


20,   21, 22 мартта “Татар теле һәм әдәбиятынын ин яхшы укытучысы”   Ботенроссия бәйгесе Казан шәһәренен “Адымнар - белемгә һәм татулыкка юл”   полилингваль комплексы базасында Татарстан Республикасыннан 20 педагог   һәм Россия Федерациясе тобәкләреннән - Мордовия, Марий Эл, Чуваш   республикаларыннан, Башкортстан, Томән, Киров, Пенза, Саратов, Тvбән   Новгород, Самар олкәләреннән, Пермь краеннан, Мәскәv шәһәреннән   укытучылар катнашты. Мордовия Республикасын Кадошкино районы   “Большеполянская ООШ” мәктәбенен туган (татар) теле һәм әдәбияты   укытучысы Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева тәкъдим итте.

Һонәр  бәйгесе татар теле һәм әдәбияты укытучыларынын статусын кvтәрv,  туган  тел һәм әдәбияты укытучыларынын алдынгы педагогик тәжрибәсен һәм  белем  бирv эшчәнлеген оештыруда инновацион технологияләрне тарату  максатыннан  уздырылды. Шулай, 20-21 мартта Татарстан Республикасы   конкурсантлары дә-ресләр һәм методик остаханәләр кvрсәттеләр. Аларны ТР   Мәгарифне vстерv институты, КФУ, ТР Фәннәр академиясе хезмәткәрләреннән   торган конкурс жюрилары бәяләгән. Оч конкурс сынавы нәтижәләре буенча   (медиавизитка, дәрес, методик остаханә) конкурснын икенче этабына   vткәннәр финалда - Татарстан Республикасынын 12 татар теле һәм әдәбияты   укытучысы һәм Россия Федерациясе субъектларыннан 12 педагог ярышты. 20-21   март коннәрендә Россия Федерациясенен торле тобәкләреннән килгән 12 укытучы дәрес, сыйныф сәгате, мастер-класс, методик остаханә   бәйгеләрендә коч сынашты. Аларны Казан федераль университеты, Татарстан   Республикасынын мәгарифне vстерv институты, Казан шәһәренен мәгариф   идарәсе, Татарстан Республикасынын фәннәр академиясе белгечләре бәяләде.   Ин яхшы татар теле укытучысы 22 март конне Татарстан Республикасынын   мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин катнашында узган   пресс-конференциядән сон билгеле булды. Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева –   “Ин яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы - 2024” Ботенроссия   бәйгесенен жинvчесе. Конкурс сынауларында Зәйнәб Хосәен кызы туган

телне   ойрәнvдә инновацион технологияләрне куллану буенча vзенен ижади алымнарын кvрсәтеп, югары нәтижәгә иреште. Ярыш нәтижәләре буенча   “Йорәгемне балаларга бирәм” номинациясендә жинvче булды. Ярышта алган   хис-кичерешләре белән Зәйнәб Хосәен кызы уртаклашты:



-   Мин Казан шәһәренен “Адымнар - белемгә һәм татулыкка юл” полилингваль комплексы Рамиль Гомәр улы Ханнанов житәкләгән 5нче сыйныфтагы 35   укучынын уникесе белән дәрес vткәрдем. Укучыларым тәрбияле, белемле,   актив булдылар, ә житәкчеләре – зур хәреф белән язылган педагог. Үземне   vз мәктәбемдә кvк хис иттем; педагогик тәжрибәм белән уртаклашырга унай   мохит тудырылган иде.
Тулаем алганда, чараны Татарстан мәгариф һәм   фән министрлыгы югары дәрәжәдә оештырган: житәкчеләренә һәм бvлек   белгечләренә - Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы бvлеге   житәкчесе Гулия Фархат кызы Мусина белән Тобәкара хезмәттәшлек   секторынын баш белгече Әлфия Гафиятулла кызы Әхәтовага, профессионаллар   буларак кинәшләре, чын-чынлап конкурсантлар очен янып йоргәннәре очен   зур-зур рәхмәтләремне белдерәм. Конкурснын һәрбер этабы уйланылган,   югары дәрәжәдә оештырылган иде. Шуна да конкурсантлар буларак vзебезне   иркен хис итеп, белгәннәребез белән уртак-лаша алдык. Татарстан укытучы абруен vстерә, укытучыны хормәт итә һәм киләчәк буынны тиешле дәрәжәдә   белемле итеп, тәрбияле итеп vстерергә тырышулары турында инандык.   Зур-зур рәхмәтләремне ярышта катнашкан хезмәттәшләремә белдерәм. Без   дуслашып, туганнар тосле бер-беребезгә ярдәмләшеп ярыштык!
Язмышыма   рәхмәтле мин. Бик тату коллективта эшлим. Ин беренче чиратта Кадошкино  районы “Большеполянская ООШ” мәктәбенен житәкчесе Светлана Наиль кызы Кильдеевага һәм коллективыма чиксез зур рәхмәтемне белдерәм. Алар мина ышандылар, коллективым мина таяныч булып, гел ярдәм кулы сузып торалар. Унышымнын саллы олешен алар белән бергә ирештем.

**Наилә НАСЫРОВА**